ГЛАВНОЕ УПРАВЛЕНИЕ
ВЕТЕРИНАРИИ
КАБИНЕТА МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР
КАБИНЕТЫНЫҢ
БАШ ВЕТЕРИНАРИЯ ИДАРӘСЕ

**БОЕРЫК** **БОЕРЫК**

10.07.2015 Казан ш. № 286-к

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Баш ветеринария идарәсенә килгән гражданнарның мөрәҗәгәтьләренә анализ үткәрү тәртибен раслау буенча

“Россия Федерациясе гражданнары мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында” 2006 елның 2 маендагы Федераль законның 14 статьясын, “Татарстан Республикасында гражданнарның мөрәҗәгәтҗләре турында” 2003 елның 12 маендагы 16-ЗРТ номерлы Законның 14 статьясын үтәү һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Баш ветеринария идарәсенә гражданнар мөрәҗәгатьләре керүгә йогынты ясый торган сәбәпләрне ачыклау һәм бетерү максаты белән боерык бирәм:

1. Шушы боерык кушымтасына туры китереп, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Баш ветеринария идарәсенә килгән гражданарның мөрәҗәгатьләренә анализ үткәрү тәртибен (алга таба – Тәртип) расларга.

2. Ветеринария эшен оештыру бүлеге башлыгына (И.Г.Сөләйманов) эшне оештырырга, мәгълүмати тәэмин итәргә һәм Тәртипнең үтәлешен контрольдә тотарга.

3. Әлеге Боерыкның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты
Баш ветеринария идарәсе башлыгы –
Татарстан Республикасы
Баш дәүләт ветеринария инспекторы А.Г.Хисаметдинов

Татарстан Республикасы Министрлар
Кабинеты Баш ветеринария идарәсенең
10.07.2015 № 286-к боерыгы белән расланды

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Баш ветеринария идарәсенә килгән гражданнарның мөрәҗәгәтьләренә анализ үткәрү тәртибе

I. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Баш ветеринария идарәсенә (алга таба – Ветеринария идарәсе) килгән гражданнарның мөрәҗәгәтьләренә анализ үткәрү тәртибе (алга таба – Тәртип) “Россия Федерациясе гражданнары мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында” 2006 елның 2 маендагы Федераль законның 14 статьясы һәм “Татарстан Республикасында гражданнарның мөрәҗәгәтҗләре турында” 2003 елның 12 маендагы 16-ЗРТ номерлы Законның 14 статьясын үтәү максаты белән эшләнгән.

1.2. Бу Тәртиптә Ветеринария идарәсенә килгән гражданнарның мөрәҗәгатьләренә анализ үткәрүнең критерийлары һәм шартлары билгеләнә.

II. Гражданнарның мөрәҗәгатьләренә анализ үткәрү тәртибе

2.1. Ветеринария идарәсенә килгән гражданнарның мөрәҗәгатьләренә анализ ярты ел һәм узып киткән ел йомгаклары буенча ветеринария эшен оештыру бүлегенең җаваплы эшчесе (алга таба – Бүлек) белән хисап чорыннан соң килүче айның 20 көненнәндә соңга калмыйча гамәлгә ашырыла. Гражданнарның Ветеринария идарәсенә килгән мөрәҗәгатьләренә үткәрелгән анализ нәтиҗәләре буенча хисап чоры өчен Ветеринария идарәсенә килгән гражданнарның мөрәҗәгатьләренә анализ турында хисап (алга таба - Хисап) рәсмиләштерелә.

2.2. Ветеринария идарәсенә гражданнардан кергән мөрәҗәгатьләргә Анализ ясау Бүлекнең җаваплы белгече тарафыннан “Электрон Хөкүмәт” Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының электрон документлар әйләнеше бердәм ведомствоара системасын кулланып башкарыла.

2.3. Ветеринария идарәсенә гражданнардан кергән мөрәҗәгатьләрне анализлау бүлеге белгече үткәргән тикшерү нәтиҗәләре буенча Ветеринария идарәсендә гражданнар мөрәҗәгатьләре белән эшләү буенча аналитик белешмә (алга таба - аналитик белешмә) рәсмиләштерелә.

2.4. Аналитик белешмә үз эченә түбәндәге мәгълүматны алырга тиеш (хисап чорында):

2.4.1. килгән, башка адресларга җибәрелгән һәм каралган язмача мөрәҗәгатьләрнең гомуми саны турында;

2.4.2. электрон документ рәвешендә килгән, башка адресларга җибәрелгән һәм каралган мөрәҗәгатьләр саны турында;

2.4.3. гражданнарны кабул иту урыннары, көннәре һәм вакыты турында;

2.4.4. шәхсән кабул ителгән гражданнар саны турында;

2.4.5. гражданнарны шәхсән кабул итү вәкаләте бирелгән затлар турында;

2.4.6. вәкаләтле затлар тарафыннан урынга чыгып башкарылган һәм шәхсән кабул итү саны турында;

2.4.7. мөрәҗәгатьләрнең тематикасы турында;

2.4.8. мөрәҗәгатьләрне карау нәтижәләре буенча кабул ителгән чаралар, шул исәптән кабул ителгән норматив хокукый һәм бүтән актлар (булган очракта) турында мәгълүмәт.

## III. Иомгаклау нигезләмәләре

3.1. Шушы Тәртипкә карата барлык үзгәрешләр һәм өстәмәләр Ветеринария идарәсе башлыгы тарафыннан раслана.